РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Старая Икшурма, ул. Ленина, д.17
тел. (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел. (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

19.12.2023 №28

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 08.11.2021 ел, №29 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 12.10.2023 елның 01-54/7098 номерлы тәкъдим ителгән куркыныч индикаторлары турындагы хатын караганнан соң, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советы Карар итә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 08.11.2021 ел, №29 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә (алга таба – положение тексты буенча) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаны яна редакциядә Кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге рәсми сайтында hhttp://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы А.И.Биккинин

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 19.12.2023 елгы 28 нче номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Муниципаль контроль үткәргәндә контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары**

1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырылган очракта.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган хезмәтләр, күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләр.